ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 декабрь, 2025 ел № 3/8

Шәһәр Советының 2024 елның 1 июлендәге 34/9 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу тәртибен камилләштерү максатында һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 9 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2024 елның 1 июлендәге 34/9 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2024 елның 30 октябрендәге 37/7, 2025 елның 27 мартындагы 43/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә**:**

1) 14 статьяның 44 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:


«44. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары:

1) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар. Территорияләрне комплекслы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган территорияләр;


2) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр куела торган территорияләр.

3) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына кушымта: Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы. Мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре картасы. Махсус саклanылучы табигать территорияләре чикләре картасы.

**ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОДСКОГО ОКРУГА ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ. ТЕРРИТОРИАЛЬНЫЕ ЗОНЫ. ТЕРРИТОРИИ, В ГРАНИЦАХ КОТОРЫХ ПРЕДУСМАТРИВАЕТСЯ ОСУЩЕСТВЛЕНИЕ КОМПЛЕКСНОГО РАЗВИТИЯ ТЕРРИТОРИИ



ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОДСКОГО ОКРУГА ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ. ТЕРРИТОРИИ, В ГРАНИЦАХ КОТОРЫХ ПРЕДУСМАТРИВАЮТСЯ ТРЕБОВАНИЯ К АРХИТЕКТУРНО-ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОМУ ОБЛИКУ ОБЪЕКТОВ КАПИТАЛЬНОГО СТРОИТЕЛЬСТВА



**ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОДСКОГО ОКРУГА ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
КАРТА ГРАНИЦ ЗОН С ОСОБЫМИ УСЛОВИЯМИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ТЕРРИТОРИЙ. КАРТА ГРАНИЦ ТЕРРИТОРИЙ ОБЪЕКТОВ КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ. КАРТА ГРАНИЦ ОСОБО ОХРАНЯЕМЫХ ПРИРОДНЫХ ТЕРРИТОРИЙ



2) 15 статьяның 46 пунктында таблицага түбәндәге эчтәлекле 24 пункт өстәргә:

| №№ т/б | Зона индексы | Исеме | Тасвирлау |
|---|---|---|---|
| 24 | **ООПТ** | Махсус сакланылучы табигать территорияләре зонасы | Махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләре. Тулысы белән шәһәр төзелеше регламенты билгеләнмәгән торак пункт территориясендә урнашкан «Боровецкие ключи» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле. Махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә урнашкан җирләрдән яисә җир участокларыннан (махсус сакланылучы табигать территорияләре составына кертелгән торак пунктлар территорияләреннән тыш) файдалану махсус сакланылучы табигать территориясе турындагы нигезләмәдә махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар нигезендә билгеләнә. |

3) 16 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. Территорияне комплекслы үстерү күздә тотылган һәм капиталь төзелеш объектларының архитектура, шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр куелган территорияләр исемлеге

49. Территорияне комплекслы үстерү күздә тотылган һәм капиталь төзелеш объектларының архитектура, шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр куелган территорияләр:

1) Кагыйдәләр составындагы «Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар. Территорияләрне комплекслы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру каралган территорияләр» картасында территорияне комплекслы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру күздә тотылган түбәндәге территорияләр билгеләнә:

| №№ т/б | Территориянең уникаль тәртип номеры |
|---|---|
| 1 | 1 |

2) Кагыйдәләр составындагы «Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр куела торган территорияләр» картасында капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр куела торган түбәндәге территорияләр билгеләнә:

| Территория тибы (№) |
|---|
| 1 |
| 2 |
| 3 |

4) 18 статьяның 57 пунктында «Җир участокларының чик үлчәмнәре (ж.у.) һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары (ОКС)» таблицасында «4.4 –кибетләр» рөхсәт ителгән файдалану төрен түбәндәгечә бәян итәргә:

| Рөхсәт ителгән файдалану төрләре | | Җир участокларының чик үлчәмнәре (ж.у.) һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары(ОКС) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Код | Исеме | Ж.у мәйданы (кв. м.) | Алгы чикнең киңлеге (м) | Ж.у. чикләрендә төзелеш процент (%) | Кат саны (кат) | Биналар, корылмалар, төзелмәләр биеклеге (м) | Ж.у. алгы / башка чикләреннән ОКС тайпылышы (м) |
| | | мин./макс | мин. | макс. | макс. | макс. | мин. |
| ШАРТЛЫ РӨХСӘТ ИТЕЛГӘН | | | | | | | |
| 4.4 | Кибетләр | 1000/2500 | б-ми | б-ми | 2 | 7 | 3/3 |

5) 18 статьяда түбәндәге эчтәлектәге 81.1 пункт өстәргә:

«81.1 махсус саклanылучы табигать территорияләре зонасы (ООПТ)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 18 апрелендәге 91/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча Методик таләпләрнең 48 пункты нигезендә шәһәр төзелеше регламенты билгеләнмәгән махсус саклanылучы табигать территориясе чикләрендәге территориаль зона.

| Рөхсәт ителгән файдалану төрләре | | Җир участокларының чик үлчәмнәре (ж.у.) һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары(ОКС) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Код | Исеме | Ж.у мәйданы (кв. м.) | Алгы чикнең киңлеге (м) | Ж.у. чикләрендә төзелеш процент | Кат саны (кат) | Биналар, корылмалар,төзелмәләр биеклеге (м) |

| Рөхсәт ителгән файдалану төрләре | | Җир участокларының чик үлчәмнәре (җ.у.) һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары(ОКС) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | (%) | | |
| | | мин./макс | макс. | макс. | макс. | мин. |
| **ТӨП** | | | | | | |
| - | - | - | - | - | - | - |
| **ШАРТЛЫ РӨХСӘТ ИТЕЛГӘН** | | | | | | |
| - | - | - | - | - | - | - |
| **ЯРДӘМЧЕ** | | | | | | |
| - | - | - | - | - | - | - |

Искәрмә: җирләрдән файдалану Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге табигать ядкарьләре турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2019 елның 29 мартындагы 237 номерлы карары белән билгеләнә;»;

6) түбәндәге эчтәлектәге 12 бүлек өстәргә:

«12 бүлек. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр

21 статья. Җир участокларыннан һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төрләре өчен капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше күренешен килештерү таләп ителми:

| Код | Җир участокларыннан һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре исеме |
|---|---|
| 2.1 | Шәхси торак төзелеше өчен |
| 2.4 | Күчемле торак |
| 2.7.2 | Шәхси ихтыяҗлар өчен гаражлар урнаштыру |
| 3.1.1 | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү |
| 3.4.2 | Стационар медицина хезмәте күрсәтү |
| 3.4.3 | Махсус билгеләнештәге медицина оешмалары |
| 3.7.1 | Дини йолалар үткәрү |
| 3.9.1 | Гидрометеорология һәм аның белән арадаш өлкәләрдәге эшчәнлекне тәэмин итү |
| 3.9.3 | Фәнни сынаулар үткәрү |
| 3.10.2 | Хайваннар өчен приютлар |
| 4.9.2 | Транспорт чаралары кую урыны |
| 5.1.1 | Спорт-тамаша чараларын тәэмин итү |
| 5.1.3 | Спорт белән шөгыльләнү мәйданчыклары |
| 5.1.4 | Спорт белән шөгыльләнү өчен җиһазландырылган мәйдачыклар |

| | |
|---|---|
| 5.4 | Кечкенә суднолар өчен причаллар |
| 5.5 | Гольф уйнау яки атта йөрү өчен кырлар |
| 6.1 | Казылма байлыклар эзләү һәм чыгару |
| 6.1.1 | Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру |
| 6.7 | Энергетика |
| 6.8 | Элемтә |
| 7.1.1 | Тимер юл |
| 7.2.1 | Тимер юлларны урнаштыру |
| 7.2.3 | Гомуми файдаланудагы транспорт кую урыны |
| 7.5 | Торбаүткәргеч транспорт |
| 8.0 | Оборона һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү |
| 8.1 | Кораллы көчләрне тәэмин итү |
| 8.3 | Эчке хокук тәртибен тәэмин итү |
| 8.4 | Җәзаларны үтәү эшчәнлеген тәэмин итү |
| 9.0 | Табигатьне махсус саклау һәм өйрәнү |
| 9.1 | Табигать территорияләрен саклау |
| 9.1.1 | Хайваннарның сирәк һәм (яисә) юкка чыгу куркынычы яный торган төрләрен саклау һәм репродукцияләү |
| 9.2 | Курорт эшчәнлеге |
| 9.3 | Тарих-мәдәният эшчәнлеге |
| 11.0 | Су объектлары |
| 11.1 | Су объектларын гомуми файдалану |
| 11.2 | Су объектларын махсус файдалану |
| 11.3 | Гидротехник корылмалар |
| 12.0 | Гомуми файдаланудагы җир участоклары (территорияләр) |
| 12.0.1 | Урам-юл челтәре |
| 12.0.2 | Территорияне төзекләндерү |
| 12.1 | Ритуаль эшчәнлек |
| 12.2 | Махсус эшчәнлек |
| 12.3 | Запас |
| 13.0 | Гомуми билгеләнештәге җир участоклары |
| 13.1 | Яшелчә бакчачылыгы |
| 13.2 | Җиләк-җимеш бакчачылыгы |

83. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр куела торган территория № 1

| **1. Капиталь төзелеш объектларының күләм-пространство характеристикаларына таләпләр** | | |
|---|---|---|
| | Минималь | Максималь |

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 Күпфатирлы торак йортлардагы коммерциягә караган биналарның беренче катының биеклеге (кертеп төзелгән, янкормалы торак булмаган биналары булмаган күпфатирлы йортлардан тыш) (м) | 3,5 | 6,5 |
| 1.2 Беренче катның идәне (м) | 0 | 0,45 |
| 1.3 Түбәнең рөхсәт ителгән конфигурацияләре | - бер яклы;<br>- ике яклы;<br>- вальма;<br>- күпкыскычлы;<br>- чатырсыман;<br>- яссы. | |
| **2. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-стилистик характеристикаларына таләпләр** | | |
| | Минималь | Максималь |
| 2.1 Күпфатирлы торак йортлардагы коммерциягә караган биналарның беренче катындагы фасад чишелешләре өчен яктылык үткәрүче конструкцияләрнең проценты (кертеп төзелгән, янкормалы торак булмаган биналары булмаган күпфатирлы йортлардан тыш) (%) | 50 | 80 |
| 2.2 Күпфатирлы торак йортлардагы коммерциягә караган биналарның беренче катындагы тәрәзә уемнарының биеклеге (кертеп төзелгән, янкормалы торак булмаган биналары булмаган күпфатирлы йортлардан тыш) (%) (м) | 2,0 | б-ми |
| 2.3 Капиталь төзелеш объектлары фасадларында декоратив гамәли сәнгать элементлары [1] | Мозаика, панно, мурал, барельеф, горельеф, контррельеф, витраж | |
| **3. Капиталь төзелеш объектларының архитектура күренешен билгели торган бизәкләү һәм (яисә) төзелеш материалларына таләпләр** | | |
| 3.1 Капиталь төзелеш объекты элементларын бизәү материалларының рөхсәт ителгән исемлеге | А) *Түбә, түбә элементлары, шулай ук козыреклар һәм япмалар*: фальц түбә, йомшак чирәп, сыек матдә кулланып эшләнгән түбә, фиксацияле засыпка, ком-цемент чирәп түбә, керамик чирәп түбә, яшелләндерелгән түбә, яктылык үткәрүче конструкцияләр;<br>Б) *Цоколь*: табигый таш, тышлау өчен көпшәк булмаган кирпеч (клинкер, керамик, гиперпрессланган), бетон композитлардан | |

| | | |
|---|---|---|
| | панельләр[2], бетон;<br>В) *Тышкы чикләүче конструкцияләр*: тышлау өчен көпшәк булмаган кирпеч (клинкер, керамик, гиперпрессланган), тышлау өчен япма конструкцияләр[3] (металлокассеталар (шул исәптән профильләштерелгән), HPL-панель, клинкер плитка, табигый таш, фиброцемент плита, композит), архитектура бетоны (фибробетон), стемалит, агач һәм агачны имитацияләүче материаллар, стеклофибробетон;<br>Г) *Тәрәзә һәм ишек уемнарын тутыру*: стеклопакеттан эшләнгән яктылык үткәрүче конструкцияләр;<br>Д) *Тоташ пыялалы лоджия/балконнарның аскы өлеше:* стемалит, пыяла, декоратив рәшәткә, перфорацияләнгән металл, фасадның төп өслеге материалы; | |
| | Минималь | Максималь |
| 3.2 Үтә күренмәле материалларның яктылык үткәрүчәнлеге проценты (%) | 50 | б-ми |
| 3.3 Штукатурлау технологиясен кулланган очракта, штукатурланган өслекләр мәйданы проценты (%) | б-ми | фасад өслегенең гомуми мәйданының 50% |
| **4. Капиталь төзелеш объектларының фасадларында һәм түбәләрендә техник һәм инженерлык җиһазларын урнаштыруга таләпләр** | | |
| | Минималь | Максималь |
| 4.1 Техник һәм инженерлык җиһазларын урнаштыруның җир дәрәҗәсеннән биеклеге (м) | 2,5 | б-ми |
| 4.2 Техник һәм инженерлык җиһазларының фасад яссылыгыннан чыгуы (м) | б-ми | 0,5 |
| 4.3 Фасадта техник һәм инженерлык җиһазларын урнаштыру төрләре | - яшерен монтаж;<br>- маскировкалау киртәләре (перфорацияләнгән металл, жалюзи, кәрзиннәр) ярдәмендә;<br>- түбәдә;<br>- яңгыр һәм кар суларын агызу өчен яшерен һәм эчке су агызгыч;<br>- кондиционер конденсаты өчен бердәм су агызгыч. | |
| **5. Капиталь төзелеш объектлары фасадларын яктыртуга таләпләр [4]** | | |
| | Минималь | Максималь |
| 5.1 Төс температурасы (Кельвин) | 3400 | 7000 |
| 5.2 5.2 Архитектура буенча мәҗбүри яктыртылырга тиешле капиталь төзелеш объектлары өлешләре | Гомуми файдалану территориясенә ориентлашкан капиталь төзелеш объектлары фасадлары | |

| | |
|---|---|
| 5.3 Архитектура яктырту төрләре | - *Тулы яктырту (заливающее освещение) (торак билгеләнешендәге капиталь төзелеш объектларын яктырту өчен файдаланудан тыш):* теракләрдән тулы яктырту, нокталы яктырткычлар белән тулы яктырту, линияле яктырткычлар;<br>- *Локаль* (акцентлы) яктырту: өстәмә яктырткычлар (прожекторлар яисә линияле яктырткычлар), грунт яктырткычлары, уемнар өчен өстәмә яктырткычлар;<br>- *Төс графикасы*: кайтарылучы яктылык белән линияле яктырту;<br>- *Яктыртылучы фасад*: тар оптикалы яктырткычлар, интерьер яктыртуы;<br>- *Керү төркемен яктырту*: түшәм яктырткычлары (эчкә кертелгән яисә өстән куелган), стена яктырткычлары (бра), түшәм һәм стена яктырткычлары комбинациясе. |
| 5.4 Капиталь төзелеш объектының беренче һәм икенче катларында урнаштырылган, шулай ук грунтка урнаштырылган яктырткычларны мәҗбүри җиһазлау | Саклау аксессуарлары (сукырайтуга каршы козыреклар, кәрәзле рәшәткә) |
| 5.5 Яктыртылу дәрәҗәсе (вертикаль һәм керү мәйданчыгы каршында) | 52.13330.2016 СП нигезендә билгеләнә. Кагыйдәләр җыелмасы. Табигый һәм ясалма яктырту. СНиП 23-05-95 актуальләштерелгән редакциясе* |
| 5.6 Бәйрәм яктыртуы (иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге капиталь төзелеш объектлары өчен) (мәҗбүри яктырту төренә өстәмә рәвештә) | - яктылык агымы куәтен 10% тан 100% ка кадәр кимендә 3 минут эчендә күчерергә тиешле динамик яктырту сценарийлары;<br>- гирляндалар;<br>- бәйрәм иллюминацияләре;<br>- яктылык проекцияләре (статик һәм динамик проекцияләр). |
| 5.7 Төсле яктырту | Ак төс белән сыеклhistoricandырылган катлаулы төсмерләр (ачык булмаган R,G,B каналлары) кулланып рөхсәт ителә |

[1] Капиталь төзелеш объектлары фасадларында декоратив гамәли сәнгать элементлары булмаган очракта таләпләр куелмаган дип санала.

[2] Ишек һәм тәрәзә уемнарының архитектура чишелешләрен һәм габаритларын исәпкә алып, тышлау панельләрен кисү системасын күздә тотарга. Фасадларны бизәгәндә плитә, плитә материалларын, панельләрне беркетү яшерен монтаж ысулы белән башкарылырга тиеш.

[3] тәрәзә һәм ишек сөзәклекләрен бизәү өчен фасадның төп өслеге материалларыннан файдалану рөхсәт ителә

[4] Капиталь төзелеш объектын архитектура ягыннан яктырту булмаган очракта, таләпләр куелмаган дип санала

84. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр куела торган территория № 2

| | | |
|---|---|---|
| 1. **Капиталь төзелеш объектларының күләм-пространство характеристикаларына таләпләр** | | |
| | Минималь | Максималь |
| 1.1 Беренче катның идәне (м) | 0 | 0,45 |
| 1.2 Түбәнең рөхсәт ителгән конфигурацияләре | - бер яклы;<br>- ике яклы;<br>- яссы. | |
| 2. **Капиталь төзелеш объектларының архитектура-стилистик характеристикаларына таләпләр** | | |
| | Минималь | Максималь |
| 2.1 Яктылык үткәрүче конструкцияләрнең проценты (%)[1] | 80 | б-ми |
| 2.2 Тәрәзә уемнары биелеге (м)[1] | 2,0 | б-ми |
| 2.3 Капиталь төзелеш объектлары фасадларының декоратив гамәли сәнгать элементлары [2] | Мозаика, панно, мурал, барельеф, горельеф, контррельеф, витраж | |
| 3. **Капиталь төзелеш объектларының архитектура күренешен билгели торган бизәкләү һәм (яисә) төзелеш материалларына таләпләр** | | |
| 3.1 Капиталь төзелеш объекты элементларын рөхсәт ителгән бизәү материаллары исемлеге | А) *Түбә, түбә элементлары, шулай ук козыреклар һәм япмалар*: фальц түбә, сыек матдә кулланып эшләнгән түбә, фиксацияле засыпка, яшелләндерелгән түбә, яктылык үткәрүче конструкцияләр;<br>Б) *Цоколь*: табигый таш, тышлау өчен көпшәк булмаган кирпеч (клинкер, керамик, гиперпрессланган), бетон композитлардан панельләр, бетон;<br>В) *Тышкы чикләүче конструкцияләр*: тышлау өчен көпшәк булмаган кирпеч (клинкер, керамик, гиперпрессланган), тышлау өчен япма конструкцияләр[3] (табигый таш), архитектура бетоны (фибробетон), стемалит, агач һәм агачны имитацияләүче материаллар, стеклофибробетон;<br>Г) *Тәрәзә һәм ишек уемнарын тутыру*[4]: стеклопакеттан эшләнгән яктылык үткәрүче конструкцияләр; | |
| 4. **Капиталь төзелеш объектларының фасадларында һәм түбәләрендә техник һәм инженерлык җиһазларын урнаштыруга таләпләр** | | |
| | Минималь | Максималь |

| | | |
|---|---|---|
| 4.1 Техник һәм инженерлык җиһазларын урнаштыруның җир дәрәҗәсеннән биеклеге (м) | 2,5 | б-ми |
| 4.2 Фасадта техник һәм инженерлык җиһазларын урнаштыру төрләре | - яшерен монтаж;<br>- маскировкалау киртәләре (перфорацияләнгән металл, жалюзи, кәрзиннәр) ярдәмендә;<br>- түбәдә;<br>- яңгыр һәм кар суларын агызу өчен яшерен һәм эчке су агызгыч;<br>- кондиционер конденсаты өчен бердәм су агызгыч. | |
| 5. **Капиталь төзелеш объектлары фасадларын яктыртуга таләпләр** [5] | | |
| | Минималь | Максималь |
| 5.1 Төс температурасы (Кельвин) | 3400 | 7000 |
| 5.2 Капиталь төзелеш объектының беренче һәм икенче катларында урнаштырылган, шулай ук грунтка урнаштырылган яктырткычлар | Саклау аксессуарлары (сукырайтуга каршы козыреклар, кәрәзле рәшәткә) | |
| 5.3 Яктыртылу дәрәҗәсе (вертикаль һәм керү мәйданчыгы каршында) | 52.13330.2016 СП нигезендә билгеләнә. Кагыйдәләр җыелмасы. Табигый һәм ясалма яктырту. СНиП 23-05-95 актуальләштерелгән редакциясе*. | |
| 5.4 Яктырту сценарие | Егерме өч сәгатьтән соң яктылык агымының кимүе (5.3 пункт нигезендә яктылык нормаларының минималь күрсәткеченә кадәр кими) | |
| 5.5 яктылык тишеменең юнәлеше | - фасадка;<br>- фасад буйлап;<br>- аска. | |
| 5.6 Төсле яктырту | Ак төс белән сыекландырылган катлаулы төсмерләр (ачык булмаган R,G,B каналлары) кулланып рөхсәт ителә | |

[1] Җир участокларыннан һәм капиталь төзелеш объектларыннан «шифаханә эшчәнлеге» (код 9.2.1) рөхсәт ителгән файдалану төре өчен билгеләнми.

[2] Капиталь төзелеш объектлары фасадларында декоратив гамәли сәнгать элементлары булмаган очракта, таләпләр билгеләнмәгән дип санала.

[3] Архитектура чишелешләрен һәм ишек, тәрәзә уемнарының габаритларын исәпкә алып, тышлау панельләрен кисү системасын күз алдында тотарга. Фасадларны бизәгәндә плитәләрне, плитә материалларын, панельләрне беркетү яшерен монтаж ысулы белән башкарылырга тиеш.

[4] Тәрәзә һәм ишек сөзәклекләрен бизәү өчен фасадның төп өслеге материалларыннан файдалану рөхсәт ителә

[5] Капиталь төзелеш объектын архитектура ягыннан яктырту булмаган очракта, таләпләр куелмаган дип санала

85. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр куела торган территория № 3

| | |
|---|---|
| **1. Капиталь төзелеш объектларының архитектура-стилистик характеристикаларына таләпләр** | |
| 1.1 2.3 Капиталь төзелеш объектлары фасадларының декоратив гамәли сәнгать элементлары [1] | Мозаика, панно, мурал. |
| **2. Капиталь төзелеш объектларының архитектура күренешен билгели торган бизәкләү һәм (яисә) төзелеш материалларына таләпләр** | |
| 2.1 Гомуми файдаланудагы территорияләргә караган яисә гомуми файдаланудагы территорияләрдән күренә торган капиталь төзелеш объектлары фасадларын бизәү өчен рөхсәт ителгән бизәү материаллары исемлеге | Табигый таш, штукатурка, тышлау өчен кирпеч, тышлау өчен фасад плитәләре[2] (металлокассеталар, шул исәптән профиль, HPL-панель, композит), пыяла агач һәм агачны имитацияләүче материаллар, металл (шул исәптән перфорацияләнгән), архитектура бетоны (фибробетон). |

[1] Капиталь төзелеш объектлары фасадларында декоратив гамәли сәнгать элементлары булмаган очракта, таләпләр билгеләнмәгән дип санала.

[2] Архитектура чишелешләрен һәм ишек, тәрәзә уемнарының габаритларын исәпкә алып, тышлау панельләрен кисү системасын күз алдында тотарга. Фасадларны бизәгәндә плитәләрне, плитә материалларын, панельләрне беркетү яшерен монтаж ысулы белән башкарылырга тиеш.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев